СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**07 октябрь 2019 ел** **№ 104**

## Сеҗе авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына яраклаштырып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2019 елның 3 октябрендәге 142 номерлы карары, Сеҗе авыл җирлеге Советының «Референдум үткәрүдә инициатива күрсәтү турында» 2019 елның 3 октябрендәге 101 номерлы карары нигезендә Сеҗе авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. 2019 елның 24 ноябренә Сеҗе авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
"2020 елда сез Сеҗе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 1 нче группа инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- Курса-Почмак авылында спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, аның территориясен төзекләндерү;
- Иске Муй авылында яшел үсентеләрне санитар кисү;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;
- Мөрәле авылында, Курса тимер юл разъездында кече архитектура формалары сатып алу һәм балалар мәйданчыкларын төзекләндерү;
- Мөрәле авылы чишмәсен төзекләндерү һәм ремонтлау өчен материаллар сатып алу;

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл эшләре алып бару;
- урам-юл катламы нигезен булдыру һәм вак таш түшәү:
- Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 3А йортыннан 7нче йортка кадәр, Вахитов урамы, 1нче йорттан 11нче йортка кадәр;
- Ташкич авылы, Г.Тукай ур., 20 нче йорттан 28 нче йортка кадәр;
- Мөрәле авылы, Үзәк урам, 52 нче йорттан 53нче йортка кадәр, 9 Май урамы, 1нче йорттан киселешкә кадәр 100м; Күпер урамы, 13нче йорттан 14нче йортка кадәр (икенче этап);
Починок-Поник авылы, Ф.Бикбаев ур., 9нчы йорттан киселешкә кадәр 100м;
- Курса-Почмак авылы, Чокыр урамы, 4 нче йорттан 14 нче йортка кадәр; М. Җәлил урамы, 30нчы йорттан киселешкә кадәр 100 м; Үзәк урам, 16 нчы йорттан 55 нче йортка кадәр юлларны ремонтлау;
- Иске Масра авылы, Киров урамы, 22 нче йорттан 23 нче йортка кадәр (икенче этап); 1 Май урамы, 1нче йорттан 5 нче йортка кадәр; 1 Май урамы, 7 нче йорттан 9 нчы йортка кадәр (икенче этап);
-Югары Масра авылы, Калинин урамы, 1нче йорттан 3нче йортка кадәр;
- Гөберчәк авылы, М. Мәһдиев ур., 89 нчы йорттан 93 нче йортка кадәр, 94 нче йорттан 96 нчы йортка кадәр; Г.Ахунов ур., 32 нче йорттан 35 нче йортка кадәр юлларны ремонтлау;
- Казаклар авылы, Ю.Гагарин ур.,19 нчы йорттан 25 нче йортка кадәр;
34 нче йорттан 35 нче йортка кадәр (икенче этап);
- Сикертән авылы, Үзәк урам, 32 нче йорттан 35 нче йортка кадәр; Мәктәп урамы, 58 нче йорттан киселешкә кадәр 100м;
-Чөмә-Елга авылы, Кооператив урамыннан З.Гомәрова урамы киселешенә кадәр 100м;
-Яңа Чүриле авылында Мәктәп һәм Сергин урамнары арасында тимер-бетон боҗралар куелган дамба ясау (3 этап);

3.Авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- Иске Муй торак пунктында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру;

4. Җирләү урыннарын карап тору:

- Чөмә-Елга авылы зираты территориясен төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаны референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә

ӘЙЕ ЮК"

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм халык күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: ТР, Арча районы, Курса-Почмак авылы, Мәктәп урамы,1; Сикертән авылы,Үзәк урам,14; Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 25.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Гыйбадуллина